**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

# КАРАР

«09» декабрь, 2021 ел

№ 860

Җир эшләрен җитештерүгә ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 пунктының 25 пунктчасы, 17 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 29 октябрендәге 724 номерлы карары белән расланган җир эшләрен җитештерүгә ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.7.1 пунктындагы 10 пунктчасын түбәндәге редакциядә чыгарырга:

«10) капиталь төзелеш объектын технологик тоташтыру эшләре башкарылган очракта, җир кишәрлеген куллануга ризалык (рөхсәт) булмау (челтәр оешмалары тарафыннан башкарыла торган энергия кабул итүче җайланмаларны технологик тоташтыру очракларыннан тыш), төзелешкә рөхсәт булмау».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында http://pestreci.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Р.Р. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

А. В. Хәбибуллин

исп. Гиниятуллина А.А.
тел.: 8(84367) 3-08-90